

Ләмберә районы депутатлар советынын чираттагы 22 нче сессиясенен кинәйтелгән утырышы vткән. Кон тәртибендәге топ мәсьәлә - 2023 елда территориянен социаль-икътисади vсешенә йомгак ясау һәм алдагы чорга бурычлар кую иде. Сессия эшендә Мордовия Республикасы Главасы Артём Алексеевич Здунов катнашкан.
2023 елдагы эш нәтижәләре һәм 2024 елга бурычлар турында топ доклад белән Ләмберә районы житәкчесе Юрий Иванович Голов чыгыш ясаган. Ул тvбәндәге эшләр турында ишеттергән. Юллар елына 17 км (якынча 550 млн сум) тозv һәм ремонтлау планлаштырыла. Президентыбызнын йокләмәсен vтәп, быел 816 йортка газ керткәннәр.
Тозекләндерv – «Заманча шәһәр мохитен формалаштыру» Федераль проекты буенча Ләмберәнен Ленин урамындагы паркны тәртипкә китерәчәкләр, ишегалды тер-риторияләрен тозекләндерvне дәвам итәчәкләр. Шулай ук Атемар авылында су алу узелы һәм су чистарту станциясе тозv мәсьәләләре хәл ителәчәкләр. Махсус объект – Атемарда калдыкларны эшкәртv буенча муниципаль-ара комплекс һәм полигон тозv - 3 млрд.сумнан артык инвестиция һәм 200дән артык яна эш урыны булыр.
Федераль программа буенча – Пензятка һәм Первомайский мәктәпләрен, планда – 2 нче Ләмберә урта гомуми белем бирv мәктәбен, Атемар мәктәбен һәм 4 балалар бакчасын капиталь ремонтлауны дәвам итәчәкләр. Берсеневка мәктәбендә спорт залын ремонтлау, Кривозерье һәм Саловка мәктәпләре очен компьютер жиһазлары сатып алу планлаштырылган.
Киләсе елда Ләмберә поликлиникасын капиталь ремонтлауны тәмамларга исәп, ФАПларны алыштыру эшен дәвам итәчәкләр. Бу – район халкынын наказлары.
Сессия нәтижәләрен йомгаклап, Мордовия Республикасы башлыгы А.А.Здунов Ләмберә районынын югары потенциалын билгеләп vткән.